Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 1**

Күки авылы 22 гыйнвар, 2019 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге башлыгының 2018 ел өчен һәм 2019 елга бурычлар турында хисабы

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 маддәсенең 5, 5.1 өлешләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 маддәсенең 7, 7.1 өлешләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының "Күки авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге башлыгы А.М. Бәдретдиновның 2018 ел өчен һәм 2019 елга бурычлар турында хисабын игътибарга алырга, эшчәнлеген канәгатьләнерлек дип танырга.

2. 2019 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге җирле үзидарә органнары алдына түбәндәге бурычлар куярга:

2.1) кризиска каршы чараларны тормышка ашыру максатларында чыгымнарны киметү һәм оптимальләштерүгә юнәлдерелгән нәтиҗәле чаралар күрергә;

2.2) акча чараларын максатчан булмаган һәм нәтиҗәсез файдалану фактларына юл куймаска;

2.3) салым базасын арттыру максатыннан авыл җирлеге территориясендә милек рәвешенә бәйсез рәвештә күчемсез мөлкәт объектларын теркәүне төгәлләү буенча чаралар үткәрергә;

2.4) шәхси ярдәмче хуҗалыкларга, индивидуаль эшкуарларга, КФХларга ярдәм программалары турында мәгълүматны халыкка җиткерергә;

3. Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлеге полиция участок вәкаләтлесе Р.Р. Вәлиуллинның хисабын игътибарга алырга, эшен канәгатьләнерлек дип танырга.

4. Күки авыл җирлеге Башкарма комитетының гражданнардан килгән хатлар, гаризалар, шикаятьләр белән эшләвен катгый контрольдә тотарга.

5.Әлеге карарны Күки авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Күки авылы, Яңа урам, 5 йорт һәм шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге Башлыгы А.М.Бәдретдинов